Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы
Борискино авылы башкарма комитеты

# КАРАРЫ

6 май 2019 ел № 8

Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы
Борискино авылы башкарма
комитеты карарларының
үз көчен югалтуын тану турында

Муниципаль норматив хокукый актларны гамәлдәге законнарга туры китерү белән бәйле рәвештә, хокукый мониторинг нәтиҗәләре буенча

Борискино авылы башкарма комитеты
КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Борискино авылы башкарма комитетының "Вәкаләтләрнең бер өлешен Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетына тапшыру турында"гы 2011 елның 15_сентябрендәге 15/1 номерлы карарының 1,2,3 пунктларын үз көчен югалткан дип танырга;

2. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Борискино авылы башкарма комитетының 2012 елның 19 сентябрендәге «Борискино авылы башкарма комитеты вәкаләтләренең бер өлешен Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетына тапшыру турында килешүгә үзгәрешләр кертү хакында 2011 елның 15 сентябрендәге" 6/1 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны Борискино авылы, Үзәк урам, 61 нче йорт; Березовка бистәсе, Үзәк урам 16 нчы йорт , территориясендә урнашкан махсус мәгълүмати стендларда халыкка җиткерергә, "Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар рәсми порталында" (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайтында «Интернет" челтәрендә урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны үз артымда калдырам.

Борискино авыл җирлеге
башкарма комитеты җитәкчесе Җ.С.Илалов